РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
БУИНСКИЙ МУНИЦИПАЛЬНЫЙ РАЙОН
СОВЕТ ВЕРХНЕЛАЩИНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БУА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
ЮГАРЫ ЛАШЧЫ АВЫЛ ЖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ

РЕШЕНИЕ КАРАР

«02» март 2020ел. 82-2 номерлы

Югары Лашчы авыл җирлеге Советының 2019 елның 23 октябрендәге 79-1 номерлы «Җир салымы турында»гы карарына үзгәрешләр кертү хакында

Россия Федерациясе Салым Кодексының 31 бүлеге, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында»гы 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә, Югары Лашчы авыл Советының «Җир салымы турында» 2019 елның 23 октябрендәге 79-1 номерлы карарын гамәлдәге законнарга туры китерү максатларында, Буа муниципаль районы Югары Лашчы авыл җирлеге Советы карар кабул итте:

I. Югары Лашчы авыл җирлеге Советының 2019 елның 23 октябрендәге «Җир салымы турында»гы 79-1 номерлы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1. 5 статьяны «Салым һәм салым буенча аванс түләүләрен түләү тәртибе һәм сроклары» түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

Салым түләүче оешмалар өчен салым түләү беренче, икенче һәм өченче кварталлар беткәннән соң, 5 май, 5 август, 5 ноябрьдән дә соңга калмыйча, җир кишәрлегенең кадастр бәясенең 1 / 4 % салым ставкасы күләмендә аванс түләүләре белән башкарыла.

Салым чоры йомгаклары буенча түләнергә тиешле салым түләү срогы үткән салым чорыннан соң килүче елның 15 февралендә билгеләнә.

II. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә һәм 2020 елның 1 гыйнварыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.

III. Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында (http:pravo.tatarstan.ru) һәм шулай ук Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре Порталында Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә (http//buinsk.tatarstan.ru) урнаштырылырга тиеш.

Татарстан Республикасы Буа муниципаль
районының Югары Лашчы авыл җирлеге башлыгы Г.Х. Усманова